| МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от 23.08.2019 № 396

Казань ш.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 9 июнендәге 182 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м :

1. “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлеген раслау турында” Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 9 июнендәге 182 номерлы боерыгы белән (2017 елның 16 гыйнварындагы 14 номерлы, 2017 елның 26 июнендәге 219 номерлы, 2017 елның 4 декабрендәге 518 номерлы, 2018 елның 11 сентябрендәге 454 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 619 номерлы Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

22.1 пунктчасының «Тукталыш пункты атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Кайбыч тукталыш пункты»;

25 пунктка түбәндәге эчтәлекле 25.11 пунктчасы өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «25.11 | Усад ав. | Усад ав. тукталыш пункты, «Көньяк парк» торак комплексы | Усад ав., «Көньяк парк» торак комплексы, Уютная ур., 4 йорт» |

«Тукталыш пунктының урнашу урыны» графасын:

30.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөслим ав., Пушкин ур., 73 йорт»;

37.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Байлар Сабасы ш.т.п., Тукай ур., 105а йорт»;

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлегенә 116 тукталыш пункты кертелгән» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлегенә 117 тукталыш пункты кертелгән, шулардан:

16 – автовокзал;

11 – автостанция;

84 – тукталыш пункты;

6 – тимер юл вокзалларында тукталыш пунктлары».

2. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты булеге мөдире Н.Н. Доброхотовка әлеге боерыкка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве уздырырга.

Министр Л.Р. Сафин